ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2021 Казан шәһәре № 11-8/тп-2021

Технологик ялгау максатларында гариза тапшыручыларга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмалары электр челтәрләренә максималь егәрлеге 15 кВт артмаган энергия кабул итү җайланмаларын (тоташтыруның әлеге ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын да исәпкә алып) технологик ялгау өчен түләү билгеләү турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары белән расланган Электр энергиясен кулланучыларның энергия кабул итү җайланмаларын, электр энергиясе җитештерү объектларын, шулай ук челтәр оешмаларыныкы һәм башка затларныкы булган электр челтәрләре хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләре, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Электр челтәрләренә технологик тоташтыру өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2017 елның 29 августындагы 1138/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Ышанычлылыкның өченче категориясенә кертелгән (электр белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча) объектларга ия булган мөрәҗәгать итүчене тоташтырганда максималь егәрлеге 15 кВт артмаган (әлеге тоташтыру ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын да исәпкә алып) энергия

кабул итү җайланмаларын Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмалары электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен, мөрәҗәгать итүче участогы чикләреннән гариза тапшырылган челтәр оешмасының мөрәҗәгать итүчегә кирәкле егәрлек дәрәҗәсенә кадәр 20 кВ кадәр егәрлек дәрәҗәсендәге электр челтәре хуҗалыгы объектларына кадәрге аралык шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмау шарты белән, 550 сум (өстәмә хак салымын исәпкә алып) күләмендә түләү билгеләргә.

2. Муниципаль районнар, шәһәр округлары чикләрендә һәм федераль әһәмияттәге шәһәрләрнең шәһәр эче территорияләрендә бер үк зат милек хокукында яки законлы башка нигездә аныкы булган, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килә торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтырган өчен 550 сум (өстәмә хак салымын исәпкә алып) күләмендәге түләп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан технологик тоташтыруга гариза тапшырылган көннән башлап киләсе гаризаны тапшырганчыга кадәр 3 ел эчендә иң күбе бер генә тапкыр технологик тоташтырттырырга мөмкин.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән технологик тоташтыру өчен түләү күләме түбәндәге очракларда кулланыла алмый:

3.1. тоташтырылачак энергия кабул итү җайланмалары урнаштырылган, бер елдан артмаган срокка төзелгән аренда килешүе буенча җир кишәрлегенең һәм (яки) капиталь төзелеш объектының хуҗасы булган затларга караган энергия кабул итү җайланмалары технологик тоташтырылган очракта;

3.2. күпфатирлы йортларның торак биналарында урнашкан энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтырганда.

4. Коммерциясез оешмаларга (гараж-төзелеш, гараж кооперативларына) карата энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру өчен, мондый берләшмәнең һәр әгъзасы тарафыннан ышанычлылыкның өченче категориясе буенча 15 кВт артмаган (электр белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча) егәрлек тоташтыру шарты белән, 20 кВ кадәр егәрлек дәрәҗәсендә челтәр оешмасы электр челтәрләренә тоташтырганда элегрәк тоташтырылган егәрлекне һәм әлеге берләшмәләрнең энергия кабул итү җайланмаларының челтәр оешмалары электр челтәре хуҗалыгының гамәлдәге объектларына кадәр шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган ераклыкта урнашкан булуын исәпкә алып, 550 сум (өстәмә хак салымын исәпкә алып) күләмендә, әлеге берләшмәләрнең әгъзалары исәбенә тапкырланган түләү билгеләргә.

5. Бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләренә карата энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтырган өчен, бакчачылык яки яшелчәчелек территориясе чикләрендә урнашкан һәр җир кишәрлегендә ышанычлылыкның өченче категориясе буенча (электр белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча) 15 кВт артмаган егәрлекне тоташтыру шарты белән, тоташтыруның әлеге ноктасына 20 кВ кадәр егәрлек дәрәҗәсендә челтәр оешмасы электр челтәрләренә тоташтырганда элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү

җайланмалары егәрлеген һәм әлеге бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләрендәге энергия кабул итү җайланмаларының челтәр оешмалары электр челтәре хуҗалыгының гамәлдәге объектларына кадәр шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган ераклыкта урнашкан булуын исәпкә алып, 550 сум (өстәмә хак салымын исәпкә алып) күләмендә, бакчачылык яки яшелчәчелек территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре санына тапкырланган түләү билгеләргә.

6. Үз гаражларын һәм хуҗалык корылмаларын (базларын, сарайларын) берләштергән гражданнарга карата энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру өчен, мондый корылмаларның һәр милекчесе тарафыннан ышанычлылыкның өченче категориясе буенча 15 кВт артмаган (электр белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча) егәрлек тоташтыру шарты белән, энергия кабул итү җайланмаларын тоташтыруның әлеге ноктасында 20 кВ кадәр егәрлек дәрәҗәсендә челтәр оешмасы электр челтәрләренә тоташтырганда элегрәк тоташтырылган егәрлекне һәм әлеге берләштерелгән корылмаларның энергия кабул итү җайланмаларының челтәр оешмалары электр челтәре хуҗалыгының гамәлдәге объектларына кадәр шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган ераклыкта урнашкан булуын исәпкә алып, 550 сум (өстәмә хак салымын исәпкә алып) күләмендә, әлеге берләшмәләрнең әгъзалары исәбенә тапкырланган түләү билгеләргә.

7. Дини оешмаларга карата энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру өчен, ышанычлылыкның өченче категориясе буенча 15 кВт артмаган (электр белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча) егәрлек тоташтыру шарты белән, энергия кабул итү җайланмаларын тоташтыруның әлеге ноктасында 20 кВ кадәр егәрлек дәрәҗәсендә челтәр оешмасы электр челтәрләренә тоташтырганда элегрәк тоташтырылган егәрлекне һәм әлеге оешмаларның энергия кабул итү җайланмаларының челтәр оешмалары электр челтәре хуҗалыгының гамәлдәге объектларына кадәр шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган ераклыкта урнашкан булуын исәпкә алып, 550 сум (өстәмә хак салымын исәпкә алып) күләмендә түләү билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Технологик ялгау максатларында гариза тапшыручыларга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмалары электр челтәрләренә максималь егәрлеге 15 кВт артмаган энергия кабул итү җайланмаларын (энергия кабул итү җайланмаларын тоташтыруның әлеге ноктасына элегрәк тоташтырылганнарын да исәпкә алып) технологик ялгау өчен түләү билгеләү турында» 2017 елның 15 декабрендәге 6-192/тп номерлы карарын көчен югалткан дип таныргa.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев